ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2025 Балык Бистәсе штп. №129пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 9 өлешендәге 18 статьясы, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.05.2025 №129пи карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча Дәүләт автоинспекциясе бүлеге (килешү буенча).

2. Автомобиль юллары хуҗасы йә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының юл хәрәкәтен оештыру схемасы эшләнә торган җирле әһәмияттәге автомобиль юллары оператив идарәсендә булган орган.